# ХӘЛИМӘ ТУТАШ

Хәлимә туташ уянып киткәндә көн бик иртә иде. Камыш пәрдә аша үтә торган кояш нуры да, әле көнгә өйрәнмәгән кебек, көннән оялган кебек кенә, зәгыйфь кенә яктылык берлә бүлмәне яктырта иде. Пәрдә ашасыннан салкынчарак чык исе исә иде.

Бер тәрәзәдән ерак кына чишмәләрнең чыкырдаулары ишетелә иде. Тирә-яктагы тынычлыкны сирәк-мирәк кенә мөңри торган сыер тавышы да бераз боза иде. Хәлимә туташ акыртын гына торып, тәрәзә янына килде, тавышсыз гына иттереп, камыш пәрдәне күтәрде. Тыштан салкынрак кына бакча һавасы ашыга-ашыга Хәлимә туташның бүлмәсенә ага башлады. Бу саф һава Хәлимә туташны бик тиз кочаклап алганга, электрик куйган кебек, аның тәннәрен чымырдатып алды. Хәлимә туташ авызын тутырып-тутырып саф һаваны сулый башлады. Ул тәрәзә төбенә утырып, тирә-якны карарга тотынды. Зур каен агачы үзенең ярты шар кебек түгәрәк яфраклары, ботаклары берлә генерал алдында басып тора торган николайский солдат кебек, селкенмәенчә-нитмәенчә тора иде. Өстке яфраклардагы энҗе бөртекләре кебек, чык тамчылары яңа кояшта ялтыр-йолтыр итеп каенның матурлыгын арттыралар иде.

Аннан ары гына шомырт агачы үзенең зөмрәд кебек яшел яфраклары берлә үзенең түм-түгәрәк, ямь-яшел асылган шомыртлары берлә, үзенең өстенә тезелгән энҗе бөртеге чыклары берлә каеннан да матур күренә иде. Ул туйга зиннәтләнгән хатын кебек киенеп-бизәнеп, үзенең сөйгәнен көтә торган кыз кебек селкенмәенчә-нитмәенчә тора иде. Аның янындагы акация агачы да, үзенең башыннан аягына кадәр сары чәчәкләренә буялып, янындагы һичбер агачка илтифат итмәенчә, үзенең матурлыгы, үзенең сафлыгы берлә ләззәтләнгән кебек була иде. Аның артыннан тагы шундый агачлар, тагы шундый чыкка бизәлгән яфраклар, тагы төрле төстәге чәчәкләр күренә. Аның теге ягында аллы-сорылы яр да тып-тын гына тора иде. Аның артында гына томаннар берлә капланып аз гына күренә торган урман да хәрәкәтсез-нисез

тора иде. Йирдәге үләннәр дә өстләренә төшкән чыкларны күтәрә алмаенча, бер якка сыгылып кына, берсе өстенә берсе сөялеп йоклаган кебек, тик торалар иде. Һәммә җир тыныч, һәммә җир моң, һәммә нәрсә хәл җыя, һәммә нәрсә киләчәк озын көндә эссе кояш берлә тартышырга хәл хәзерлиләр кебек күренә иде. Менә акрын гына җил исте. Күлнең көзге кебек шома өсте шадраланып китте, агачларның тик тора торган һавалы яфраклары да, бер-берсенә бәрелешеп, үзенә бер төсле матур гына тавыш чыгара башладылар. Энҗе бөртеге кебек чык бөртекләре берәм-берәм җиргә коела башладылар. Үләннәр дә аз гына урыннарыннан кузгалдылар. Алар да бер-ике мәртәбә башларын селкеп, авыррак чыкларын төшереп, кояшка каршы башларын күтәрделәр. Бу йил Хәлимә туташның күңеленә дә тәэсир итте, аның йоклаган уйларын уятты, ул да үзенең хәлен уйларга, үзе тугрысында фараз кылырга тотынды. Үзен-үзе белмәенчә генә, үзе нишләгәнен сизмәенчә генә зур авыр сачен алдына алып салып, аның берлә уйный-уйный, үзенең үткән гомерләрен тикшерә башлады. Алар арасында татлы минутларын эзли башлады. Әнисенең үлеп, моның үги әни кулына калуыннан башлап, бу көнгә кадәр килеп йитте. Үзенең рәхәтләнеп тордым диярлек бер минут та гомерен таба алмады. Үзенең рухани тормышыны — үзенең моңынча ниләр уйлап, нинди фикерләрдән ләззәт алганын эзләргә тотынды. Анда да яшь күңелне канәгатьләндерерлек, ут кебек кызу табигатьне ризаландырырлык бернәрсә дә таба алмады. Үзенең укыган нәрсәләрен уйларга, үзенең театрларда күргән манзарәләрен күз алдына китерергә тотынды, анда да искитәрлек бернәрсә дә таба алмады. Күңеле киләчәкне уйларга тотынды, киләчәк өчен планнар корырга башлады. Үзенең кыз булуы, үзенең татар кызы булуына, үзенең үз тормышы хакында эшләргә түгел, уйларга да правасы юклыгы хәтеренә төште. Тагы киләчәк планнары җимерелде. Тагы озын-озын уйларга чумды. Тагы, үзен-үзе онытып, иркен дөньяда, иркен яланнарда, иркен шәһәрләрдә, иркен өйләрдә, ирекле бер кеше булып, кешенең кәефен китерер өчен ясалган курчак кына булмаенча торуларын уйлый башлады. Аның бу өйдән, бу үги ана идарәсеннән чыгасы, бу зинданнан да котыласы килә башлады. Аның чын кеше булып, беркемнән

дә сорамаенча,беркемнән дә ризалык алмаенча киенәсе, йөрисе, торасы килә башлады. Ул, башка халык кызлары кебек, үзе сөйгәнне генә сөясе, үзе яратканны гына яратасы, үзе теләгән тормыш берлә генә торасы килә башлады. Ул анасының кушуы берлә йөри торган, атасының әмере берлә сөя торган, әллә нинди карчыкларның димнәре берлә, әллә кемнең хатыны була торган, әллә нинди мулланың бер-ике авыз сүзе берлә аерыла торган машиналыктан чыгасы, ул дөньядан әллә кая, еракка-еракка китәсе, ул дөньяны бөтенләй ташлыйсы, мәңгегә шул зиндан өйләрдән китәсе, гомерлеккә шул «ярамый», «килешми» богауларын өзәсе килде. Матур киң дөньяда, шундый матур бакчада, шундый тигез күлләрдә, шундый томанлы гына урманнарда үзенә-үзе хуҗа булып, үзе теләгәнчә йөрисе килде. Тагы үзенең кыз идеке, үзенең татар кызы идеке, үзенең болай уйларга, үзенең тәрәзә төбенә утырырга да правасы юклыгы хәтеренә төште.

Хәзер анасы уянып кыямәтләр куптарачагы, хәзер атасы моның шул фикерләрен белсә, моны «дөнья вә ахирәт рәхәтенә ирештерер өчен», бу бозык фикерләрдән коткарыр өчен, хәзер үк, кем очраса, шуңарга кияүгә бирәчәге хәтеренә килде.

Күз алдына караңгы өйләр, ямьсез тормышлар килә башлады. Әллә нинди «Мин ирең, мин падишаһың» дигән тавышны ишеткән кебек була башлады. Хәлимә туташ калтырый башлады. Тагы җил исте, тагы күл шадраланды, тагы агачлар акыртын гына бер-берсе берлә бәрелештеләр, сөйләштеләр, тагы чыклар шыбыр-шыбыр коелдылар, тагы Хәлимә туташ үзен үз бүлмәсендә, үги ана ихтыярында бер кыз идекен хәтеренә китерде. Андый иркенле, иректе тормышлар моның кебек мең-мең татар кызлары өчен хәрәм идеке, кеше булып дөньяда тору алар өчен гөнаһ идеке күңеленә килде дә, күзләреннән мөлдер-мөлдер энҗе бөртек яшьләре ага башлады.

Шул яшьләр берлә бергә аның өметләре, киләчәк өчен корган матур планнары да бергә китте. Ул тагы үзен-үзе шул үз өеңдә үзенең тормышының колы итеп, шул иске гадәтләрнең корбаны итеп күрә башлады.

Үзенең шул тормышыннан котылырга хәле юклыгын уйлап, тагы пәрдәсен төшерде. Тагы бүлмә караңгыланды, тагы Хәлимә туташка караңгы уйлар килә башлады, тагы Хәлимә туташ үзен-үзе правасыз татар кызы итеп хис итте.

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Зөмрәд* — зөбәрҗәт.

*Хәлимә туташ* — Хикәя беренче тапкыр «Тавыш» гәзитәсе нең 1907 ел, 30 апрель (2) санында басылган. Имзасыз. Г.Исхакыйның «Җыентык» (1909) исемле китабына кертелгән.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б. 16-18.